# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«Сәүдә (эшләр башкару, хезмәт күрсәтү), сертификацияләү, лицензияләү өлкәсендә хокук бозулар өчен, штрихлы мәҗбүри кодлаштыру тәртибен һәм бәяләрнең дәүләт дисциплинасын бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

**1 статья.** «Сәүдә (эшләр башкару, хезмәт күрсәтү), сертификацияләү, лицензияләү өлкәсендә хокук бозулар өчен, штрихлы мәҗбүри кодлаштыру тәртибен һәм бәяләрнең дәүләт дисциплинасын бозулар өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998 ел, № 8 (1 өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 2 статьяның икенче абзацында «кисәтү ясала яисә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. 3 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик затларга, индивидуаль эшкуар-сатучылар буларак теркәлгән гражданнарга, товарларын конфискацияләп яисә шунардан гайре генә, хезмәт өчен түләүнең өчтән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.».

3. 5 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик затларга, индивидуаль эшкуар-сатучылар буларак теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең өчтән алып егерме биш минималь күләменә кадәр штраф салына.».

4. 6 статьяның икенче абзацын түбәндәгечә бәян итәргә:

«кисәтү ясала яки юридик затларга, индивидуаль эшкуар-сатучылар буларак теркәлгән гражданнарга, товарларын конфискацияләп яисә аннан гайре генә, хезмәт өчен түләүнең биштән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.».

5. 7 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик затларга, индивидуаль эшкуар-сатучылар буларак теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.».

6. 10 статьяда:

беренче өлешенең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик затларга, урындагы затларга яисә индивидуаль эшкуар-сатучылар буларак теркәлгән гражданнарга (әзерләүчеләргә, башкаручыларга), товарларын конфискацияләп яисә аннан гайре генә, хезмәт өчен түләүнең биштән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.»;

икенче өлешенең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик затларга, урындагы затларга яисә индивидуаль эшкуар-сатучылар буларак теркәлгән гражданнарга (әзерләүчеләргә, башкаручыларга) хезмәт өчен түләүнең биштән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.»;

өченче өлешенең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик затларга, урындагы затларга яисә индивидуаль эшкуар-сатучылар буларак теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең биштән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.».

7. 11 статьяда:

беренче өлешенең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең биштән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.».

икенче өлешенең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең утыздан алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.».

8. 12 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сынау лабораторияләренең (үзәкләренең) урындагы затларына хезмәт өчен түләүнең биштән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.».

**2 статья.** Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 20 декабре
№ 545